ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

«Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 467-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары М.Ф. Сыровацкий, А.Г. Хәбибуллин, Р.И. Шәфигуллин тарафыннан кертелгән «Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 467-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе — Ф.Х. Мөхәммәтшин

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ АППАРАТЫ / АППАРАТ ГОСУДАРСТВЕННОГО СОВЕТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
БЕРКЕТМӘ БҮЛЕГЕ
ПРОТОКОЛЬНЫЙ ОТДЕЛ

Казан шәһәре,
2023 елның 14 сентябре
№ 2130-VI ДС

Проект
Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы депутатлары
М.Ф. Сыровацкий, А.Г. Хәбибуллин,
Р.И. Шәфигуллин
тарафыннан кертелә

**«Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында»**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

**1 статья**

«Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил турында» 2000 елның 3 мартындагы 95 номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2000, № 3 (3); 2003, № 8; 2008, № 11 (III өлеш); 2010, № 6 (I өлеш); 2011, № 8 (I өлеш); 2013, № 2 (I өлеш); 2014, № 6 (II өлеш); 2015, № 6 (II өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 41 (I өлеш); 2020, № 51 (I өлеш); 2021, № 1 (I өлеш), № 57 (I өлеш); 2022, № 49 (I өлеш), № 83 (I өлеш); 2023, № 27 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 11 статьяга түбәндәге эчтәлекле 7 өлеш өстәргә:
«7. Вәкаләтле вәкил, әгәр коррупциягә каршы көрәш максатларында «Россия Федерациясе субъектларында кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкилләр турында» 2020 елның 18 мартындагы 48-ФЗ номерлы Федераль законда (алга таба – Федераль закон), башка федераль законнарда билгеләнгән чикләүләрне, тыюларны, мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау яисә аны җайга салу таләпләрен үтәмәү һәм бу законнарда билгеләнгән бурычларны башкармау «Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 13 статьясындагы 3 – 6 өлешләрендә каралган тәртиптә вәкаләтле вәкилдән тормаган хәлләрнең нәтиҗәсе итеп танылган очракта, мондый чикләүләрне, тыюларны һәм таләпләрне үтәмәгән, шулай ук мондый бурычларны башкармаган өчен җаваплылыктан азат ителә.»;

2) 12 статьяның 3 өлешендәге 4 пунктында «Россия Федерациясе субъектларында кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкилләр турында» 2020 елның 18 мартындагы 48-ФЗ номерлы Федераль законда (алга таба – Федераль закон)» сүзләрен «Федераль законда» сүзләренә алмаштырырга.

**2 статья**

«Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында» 2003 елның 16 гыйнварындагы 3-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (2005 елның 25 октябрендәге 106-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2003, № 1; 2005, № 10 (II өлеш); 2006,

№ 12 (I өлеш); 2007, № 11; 2008, № 3, № 10 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2009, № 12 (I өлеш); 2010, № 1 – 2, № 10 (II өлеш); 2011, № 5, № 11 (I өлеш); 2012, № 7 (I өлеш); 2013, № 2 (I өлеш), № 3, № 11 (I өлеш); 2014, № 5, № 6 (II өлеш), № 7, № 12 (II өлеш); 2015, № 7 (I өлеш); 2016, № 4, № 7 – 8, № 9 (II өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 1 (I өлеш), № 85 (I өлеш); 2018, № 1 (I өлеш), № 29 (I өлеш), № 54 (I өлеш), № 78 (I өлеш); 2020, № 4 (I өлеш), № 37 (I өлеш), № 87 (I өлеш); 2021, № 1 (I өлеш), № 57 (I өлеш); 2022, № 34 (I өлеш), № 96 (I өлеш); 2023, № 27 (I өлеш), № 35 (I өлеш), № 48 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) $13^1$ статьяның 1 өлешенә түбәндәге эчтәлекле яңа бишенче җөмлә өстәргә: «Дәүләт хезмәтендә булуның иң чик яшенә җиткән, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппаратында дәүләт хезмәте вазыйфаларының баш төркеменең «җитәкчеләр» категориясендәге дәүләт хезмәте вазыйфасын биләүче дәүләт хезмәткәренә дәүләт хезмәте чоры аның ризалыгы белән, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе йә дәүләт хезмәткәрен вазыйфага билгеләп куйган башка вазыйфаи зат тарафыннан, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе белән килештереп, озайтылырга мөмкин (әмма ул 70 яшькә җиткәнчегә кадәр).»;

2) 17 статьяда:

а) $6^1$ өлештә «дөрес булмаган яисә» сүзләрен төшереп калдырырга, «белешмәләр тапшыру» сүзләреннән соң «, федераль законнарда билгеләнгән очраклардан тыш,» сүзләрен өстәргә;

б) түбәндәге эчтәлекле $6^2$ өлеш өстәргә:

«$6^2$. Дәүләт хезмәткәре тарафыннан әлеге статьяның $6^1$ өлешендә күрсәтелгән күрәләтә дөрес булмаган белешмәләр тапшыру дәүләт хезмәткәрен дәүләт хезмәтеннән азат итүгә китерерлек хокук бозу була.»;

3) $17^1$ статьяда:

а) 4 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. Дәүләт хезмәткәренең үз чыгымнары, шулай ук үз гаиләсе әгъзаларының чыгымнары турында белешмәләрне тапшырмау, әгәр мондый белешмәләрне тапшыру мәҗбүри булса, йә күрәләтә тулы булмаган белешмәләр тапшыру, федераль законнарда билгеләнгән очраклардан тыш, дәүләт хезмәткәрен дәүләт хезмәтеннән азат итүгә китерерлек хокук бозу булып тора.»;

5) түбәндәге эчтәлекле 5 өлеш өстәргә:

«5. Дәүләт хезмәткәре тарафыннан әлеге статьяның 4 өлешендә күрсәтелгән күрәләтә дөрес булмаган белешмәләр тапшыру дәүләт хезмәткәрен дәүләт хезмәтеннән азат итүгә китерерлек хокук бозу була.»;

**3 статья**

«Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты статусы турында» 2004 елның 18 мартындагы 15-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, № 3 (I өлеш); 2005, № 5; 2007, № 5; 2010, № 6 (I өлеш); 2011, № 11 (I өлеш); 2012, № 7 (I өлеш); 2013, № 3; 2014, № 5, № 11 (I өлеш), № 12 (II өлеш); 2015, № 1 – 2; 2016, № 1 – 2, № 4, № 6 (I өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 52 (I өлеш), № 94 (I өлеш); 2020, № 57 (I өлеш); 2021, № 1 (I өлеш), № 57 (I өлеш); 2023, № 3 (I өлеш), № 20 (I өлеш), № 27 (I өлеш), № 35 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) $10^1$ статьяның 1 өлешенә түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә: «Депутат, әгәр коррупциягә каршы көрәш максатларында «Россия Федерациясе субъектларында гавами хакимиятне оештыруның гомуми принциплары турында» 2021 елның 21 декабрендәге 414-ФЗ номерлы Федераль законда, башка федераль законнарда билгеләнгән чикләүләрне, тыюларны, мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау яисә аны җайга салу таләпләрен үтәмәү һәм бу законнарда билгеләнгән бурычларны башкармау «Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 13 статьясындагы 3 – 6 өлешләрендә каралган тәртиптә вәкаләтле вәкилдән тормаган хәлләрнең нәтиҗәсе итеп танылган очракта, мондый чикләүләрне, тыюларны һәм таләпләрне үтәмәгән, шулай ук мондый бурычларны башкармаган өчен җаваплылыктан азат ителә.»;

2) $17^1$ статьяның 1 өлешендә «Россия Федерациясе субъектларында гавами хакимиятне оештыруның гомуми принциплары турында» сүзләреннән соң «2021 елның 21 декабрендәге 414-ФЗ номерлы» сүзләрен өстәргә.

**4 статья**

«Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфалары турында» 2006 елның 4 мартындагы 16-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2006, № 3 (I өлеш); 2007, № 7 (I өлеш); 2008, № 7 (II өлеш), № 12 (I өлеш); 2009, № 12 (II өлеш); 2010, № 1 – 2, № 4 (I өлеш); 2011, № 5; 2012, № 7 (I өлеш); 2013, № 2 (I өлеш), № 3, № 11 (I өлеш); 2014, № 5, № 6 (II өлеш), № 7, № 12 (II өлеш); 2015, № 11 (I өлеш); 2016, № 4, № 6 (I өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 52 (I өлеш); 2018, № 1 (I өлеш); 2020, № 37 (I өлеш), № 87 (I өлеш); 2021, № 57 (I өлеш); 2022, № 83 (I өлеш); 2023, № 27 (I өлеш), № 35 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 9 статьяның 1 өлешенә түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә: «Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын биләүче затлар, әгәр коррупциягә каршы көрәш максатларында «Россия Федерациясе субъектларында гавами хакимиятне оештыруның гомуми принциплары турында» 2021 елның 21 декабрендәге 414-ФЗ номерлы Федераль законда, башка федераль законнарда билгеләнгән чикләүләрне, тыюларны, мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау яисә аны җайга салу таләпләрен

үтәмәү һәм бу законнарда билгеләнгән бурычларны башкармау «Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 13 статьясындагы 3 – 6 өлешләрендә каралган тәртиптә вәкаләтле вәкилдән тормаган хәлләрнең нәтиҗәсе итеп танылган очракта, мондый чикләүләрне, тыюларны һәм таләпләрне үтәмәгән, шулай ук мондый бурычларны башкармаган өчен җаваплылыктан азат ителә.»;

2) 13 статьяның 6 өлешендәге беренче җөмләсендә «дәүләт гарантияләре» сүзләреннән соң «, әгәр федераль законнарда башкасы каралмаган булса,» сүзләрен өстәргә, икенче җөмләне төшереп калдырырга;

3) $13^1$ статьяның 3 өлешендәге беренче җөмләсендә «дәүләт гарантияләре» сүзләреннән соң «, әгәр федераль законнарда башкасы каралмаган булса,» сүзләрен өстәргә, икенче җөмләне төшереп калдырырга.

**5 статья**

Татарстан Республикасы Сайлау кодексының 18 статьясына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2007, № 5, № 12 (I өлеш); 2010, № 6 (I өлеш); 2011, № 8 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2012, № 6 (I өлеш); 2013, № 10; 2014, № 5; 2015, № 5; 2016, № 4, № 6 (I өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 27 (I өлеш), № 52 (I өлеш), № 55 (I өлеш); 2018, № 44 (I өлеш), № 83 (I өлеш); 2019, № 2 (I өлеш), № 28 (I өлеш); 2020, № 4 (I өлеш); 2021, № 1 (I өлеш), № 29 (I өлеш), № 93 (I өлеш); 2022, № 77 (I өлеш); 2023, № 11 (I өлеш), № 27 (I өлеш), № 48 (I өлеш), аңа түбәндәге эчтәлекле $6^3$ өлеш өстәп, үзгәреш кертергә:

«$6^3$. Комиссиядә даими (штат) нигездә эшләүче хәлиткеч тавыш хокукына ия комиссия әгъзасы, әгәр коррупциягә каршы көрәш максатларында «Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль законда, башка федераль законнарда билгеләнгән чикләүләрне, тыюларны, мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау яисә аны җайга салу таләпләрен үтәмәү һәм бу законнарда билгеләнгән бурычларны башкармау «Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 13 статьясындагы 3 – 6 өлешләрендә каралган тәртиптә вәкаләтле вәкилдән тормаган хәлләрнең нәтиҗәсе итеп танылган очракта, мондый чикләүләрне, тыюларны һәм таләпләрне үтәмәгән, шулай ук мондый бурычларны башкармаган өчен җаваплылыктан азат ителә.».

**6 статья**

Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2013, № 6 (II өлеш); 2014, № 5, № 6 (II өлеш), № 12 (II өлеш); 2015, № 7 (I өлеш); 2016, № 4, № 7 – 8, № 9 (II өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 1 (I өлеш), № 17 (I өлеш), № 52 (I өлеш), № 55 (I өлеш), № 94 (I өлеш); 2018, № 1 (I өлеш), № 29 (I өлеш), № 54 (I өлеш), № 78 (I өлеш); 2019, № 2 (I өлеш), № 19 (I өлеш), № 49 (I өлеш); 2020, № 4 (I өлеш), № 37

(I өлеш), № 57 (I өлеш), № 87 (I өлеш); 2021, № 1 (I өлеш), № 57 (I өлеш); 2022, № 3 (I өлеш), № 24 (I өлеш); 2023, № 11 (I өлеш), № 27 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 17 статьяда:

а) 5 өлештә «чаралары күрелмәү» сүзләреннән соң «, федераль законнарда билгеләнгән очраклардан тыш,» сүзләрен өстәргә;

б) 7 өлештә «чаралары күрелмәү» сүзләреннән соң «, федераль законнарда билгеләнгән очраклардан тыш,» сүзләрен өстәргә;

2) 18 статьяда:

а) 7 өлештә «дөрес булмаган яисә» сүзләрен төшереп калдырырга, «белешмәләр тапшыру» сүзләреннән соң «, федераль законнарда билгеләнгән очраклардан тыш,» сүзләрен өстәргә;

б) түбәндәге эчтәлекле $7^1$ өлеш өстәргә:

«$7^1$. Муниципаль хезмәткәр тарафыннан әлеге статьяның 7 өлешендә күрсәтелгән белә торып дөрес булмаган белешмәләр тапшыру муниципаль хезмәткәрне муниципаль хезмәттән җибәрүгә китерерлек хокук бозу булып санала.»;

3) 33 статьяга түбәндәге эчтәлекле $1^1$ өлеш өстәргә:

«$1^1$. Муниципаль хезмәткәр, әгәр коррупциягә каршы көрәш максатларында «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» Федераль законда, башка федераль законнарда билгеләнгән чикләүләрне, тыюларны, мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау яисә аны җайга салу таләпләрен үтәмәү һәм бу законнарда билгеләнгән бурычларны башкармау «Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 13 статьясындагы 3 – 6 өлешләрендә каралган тәртиптә вәкаләтле вәкилдән тормаган хәлләрнең нәтиҗәсе итеп танылган очракта, мондый чикләүләрне, тыюларны һәм таләпләрне үтәмәгән, шулай ук мондый бурычларны башкармаган өчен җаваплылыктан азат ителә.».

**7 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе

**«Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы Законы проектына аңлатма**

Закон проекты Татарстан Республикасының аерым закон актларын коррупциягә каршы көрәш өлкәсендәге федераль законнарга кертелгән үзгәрешләргә туры китерүгә юнәлдерелгән.

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 10 июлендәге 286-ФЗ номерлы Федераль закон белән физик затлар, шул исәптән Россия Федерациясе субъектлары дәүләт вазыйфаларын һәм муниципаль вазыйфаларны, дәүләт граждан хезмәте һәм муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүчеләре дә, әгәр коррупциягә каршы көрәш максатларында федераль законнарда билгеләнгән чикләүләрне, тыюларны, мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау яисә аны җайга салу таләпләрен үтәмәү һәм бу законнарда билгеләнгән бурычларны башкармау мондый затлардан тормаган хәлләрнең нәтиҗәсе итеп танылган очракта, мондый чикләүләрне, тыюларны һәм таләпләрне үтәмәгән, шулай ук мондый бурычларны башкармаган өчен җаваплылыктан азат ителәләр.

Физик заттан тормаган хәлләр дип аның контроленә кермәгән, шушы шартларда көтелмәгән һәм алардан котылып булмаган йә җиңеп чыга алмаслык булган һәм коррупциягә каршы көрәш максатларында федераль законнарда билгеләнгән чикләүләрне, тыюларны, мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау яисә аны җайга салу таләпләрен үтәү һәм бурычларны башкару мөмкинлеген булдырмый торган гадәттән тыш һәм булдырмый калып булмый торган хәлләр танылa. Мондый хәлләргә, аерым алганда, табигать бәла-казалары (шул исәптән җир тетрәү, су басу, давыл), янгын, массакүләм авырулар (эпидемияләр), забастовкалар, хәрби гамәлләр, террорчылык актлары, дәүләт органнары (шул исәптән чит дәүләтләрнең дәүләт органнары) һәм җирле үзидарә органнары кабул итә торган тыю һәм чикләү чаралары керә. Даими кабатлана торган һәм фаразлана ала торган вакыйгалар һәм күренешләр, шулай ук бу хәлләрнең булуына сылтаучы физик затның ихтыярыннан һәм гамәлләреннән торган хәлләр физик заттан тормаган хәлләр дип танылa алмый.

Шуңа бәйле рәвештә, закон проекты белән түбәндәгеләргә тиешле үзгәрешләр кертелә:

– Татарстан Республикасы Сайлау кодексына;
– Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексына;
– «Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил турында» 2000 елның 3 мартындагы 95 номерлы Татарстан Республикасы Законына;
– «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында» 2003 елның 16 гыйнварындагы 3-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына;
– «Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты статусы турында» 2004 елның 18 мартындагы 15-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына;
– «Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфалары турында» 2006 елның 4 мартындагы 16-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына.

Моннан тыш, закон проекты белән «Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәте турында» Федераль законның $25^1$ статьясына үзгәреш кертү хакында» 2023 елның 24 июлендәге 357-ФЗ номерлы Федераль законның дәүләт хезмәтендә

булуның иң чик яшенә җиткән, Россия Федерациясе субъектының закон чыгару органы аппаратында дәүләт хезмәте вазыйфаларының баш төркеменең «җитәкчеләр» категориясендәге дәүләт хезмәте вазыйфасын биләүче дәүләт хезмәткәренә дәүләт хезмәте чорын озайту мөмкинлеген (әмма ул 70 яшькә җиткәнчегә кадәр) күздә тотучы нигезләмәләре дә исәпкә алынган.

**«Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы законын кабул итүгә бәйле рәвештә үз көчләрен югалтуы танылырга, туктатылып торырга, үзгәртелергә яисә кабул ителергә тиешле Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлары исемлеге**

«Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы законын кабул итүгә бәйле рәвештә Татарстан Республикасы законнарын һәм башка норматив хокукый актларын үз көчләрен югалткан дип тану, туктатып тору, үзгәртү яисә кабул итү таләп ителми.

**«Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы законы проектына финанс-икътисадый нигезләү**

«Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы бюджетыннан өстәмә финанс чараларын бүлеп бирүне таләп итми.